| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

31.05.2019 Алабуга шәһәре № 371

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2012 елның 20 апрелендә чыккан 221 номерлы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендә чыккан 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законга, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында Кодексы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2012 елның 20 апрелендә чыккан 221 номерлы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәнең 6 Пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Конкурс ике этапта уздырыла. Беренче этап конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү бастыруны үз эченә ала һәм тапшырылган документлар нигезендә конкурс комиссиясе бәйгедә катнашуга кандидатлар үткәрү турында Карар кабул итә.

Конкурста катнашырга теләүчеләр түбәндәге документларны тапшыралар:

1) муниципаль хезмәткә керү һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында үтенеч белән гариза;